РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» окябрь 2025 ел** **№ 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2025 елның 11 ноябренә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 11 ноябре 09.00 сәг тән 10.00 сәг кә кадәр;
- үткәрү урыны – Ирекле авылы, Подгорная ур., Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәл яны торриториясе дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 28 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адрес буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Ирекле авылы, Подгорная урамы үзәге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Ирекле торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Ирекле торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 000 (бер мең) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, бер тапкыр түләтүне 500 (биш йөз) сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү** (1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәленә ремонт ясау).

РИЗА КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Ирекле авылы, Подгорная урамы үзәге; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Р.К.Галимҗанова